КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 10 октябрь г.Казань № 874

Сәламәтлек саклау өлкәсендәге эшчәнлекне гамәлгә ашыручы медицина оешмалары, башка оешмалар һәм аларның аерымланган бүлекчәләре хосусый сак оешмаларыннан сатып алуларны гамәлгә ашырганда Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы буйсынуындагы объектларның (территорияләрнең) террорчылыктан сакланышын тәэмин итүгә бәйле хезмәт күрсәтүләр бәясенең нормативларын раслау турында

«Террорчылыкка каршы тору турында» 2006 елның 6 мартындагы 35-ФЗ номерлы Федераль законның 5.1 статьясындагы 2 өлешенең 7 пункты, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгы объектларының (территорияләренең) һәм Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгы эшчәнлеге өлкәсенә караган объектларның (территорияләрнең) террорчылыкка каршы якланыуына таләпләрне һәм әлеге объектларның (территорияләрнең) иминлек паспорты рәвешен раслау турында» 2017 елның 13 гыйнварындагы 8 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Сәламәтлек саклау өлкәсендәге эшчәнлекне гамәлгә ашыручы медицина оешмалары, башка оешмалар һәм аларның аерымланган бүлекчәләре хосусый сак оешмаларыннан сатып алуларны гамәлгә ашырганда Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы буйсынуындагы объектларның (территорияләрнең) террорчылыктан сакланышын тәэмин итүгә бәйле хезмәт күрсәтүләр бәясенең нормативларын беренче, икенче һәм өченче куркыныч категориясендәге сәламәтлек саклау учреждениеләре объектлары (территорияләре) һәм дүртенче куркыныч

категориясендәге сәламәтлек саклау учреждениеләренең аерым объектлары (территорияләре) өчен бер сак посты өчен сәгатенә 163 сум күләмендә расларга.

2. Хосусый сак оешмалары тарафыннан сакланырга тиешле дүртенче куркыныч категориясендәге сәламәтлек саклау учреждениеләренең аерым объектлары (территорияләре) исемлеге Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан билгеләнә.

3. Беренче, икенче, өченче куркыныч категориясендәге сәламәтлек саклау учреждениеләре объектлары (территорияләре) һәм дүртенче куркыныч категориясендәге сәламәтлек саклау учреждениеләренең аерым объектлары (территорияләре) өчен саклау постлары саны Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан билгеләнә.

4. Сәламәтлек саклау учреждениеләре объектларының (территорияләренең) террорчылыктан сакланышын тәэмин итүгә бәйле хезмәт күрсәтүләр бәясенең нормативлары, сәламәтлек саклау учреждениеләрендә финанслауның башка чыганаклары булганда, арттырылырга мөмкин.

5. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин